СОВЕТ КАТМЫШСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
МАМАДЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ул. Кирова, д.74, с. Катмыш,
Мамадышский район,
Республика Татарстан, 422177

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ КАТМЫШ АВЫЛ
ЖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

Киров урамы, 74 нче йорт, Катмыш авылы,
Мамадыш районы,
Татарстан Республикасы, 422177

Тел. (факс): (85563) 2-73-03 e-mail: Katmish.Mam@tatar.ru, www:mamadysh.tatarstan.ru

**Карар** **Решение**

“17” сентября 2018 г. № 6-36

Референдум уздыру инициативасы турында

«Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 ел, 12 июнь, 67-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясының 2 пункты, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 ел, 6 октябрь, 131-ФЗ номерлы Федераль законның 22, 56 статьялары, "Җирле референдум турында» 2004 ел, 23 март, 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 12 статьясы, «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының Катмыш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 11 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Катмыш авыл җирлеге Советы К А Р А Р КАБУЛ ИТТЕ:

1.Түбәндәге сораулар буенча җирле референдум үткәрү инициативасы белән чыгарга:

"Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Катмыш авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган гражданнарга, 1 һәм 2 группа инвалидлар, Бөек Ватан сугышы һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашкан ветераннар, Бөек Ватан сугышында һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашканнарның тол хатыннары, күп балалы гаиләләр, көндезге бүлектә белем алучы студентлар, Россия Армиясе сафларында хезмәт итүчеләрдән кала, 2019 елда 500 сум күләмендә үзара салым кертелүгә һәм ул акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен тотылуына сез ризамы:

1. Җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмиятле автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеген гамәлгә ашыру:

- Катмыш һәм Еникей Чишмә торак пунктларында юлны вакташ җәеп ремонтлау;
- авыл җирлегенә караучы юлларны тигезләү һәм кардан чистарту.

2. Җирлек халкының бергә җыелып ял итүе өчен шартлар тудыру һәм халыкның җыелып ял итү урыннарын төзекләндерү, гражданнарның гомуми файдаланудагы су объектларына һәм аларның яр буе полосаларына ирекле керә алуын тәэмин итү:

- Катмыш һэм Баскан торак пунктларында Җину һэм ял паркын төзекләндерү;
-Баскан торак пунктында "Балтач" чишмәсен төзекләндерү.
-Баскан торак пунктындда тыл ветераннары хөрмәтенә һәйкәл урнаштыру.

3. Җирлекнең торак пунктларын пожар куркынычсызлыгының төп чаралары белән тәэмин итү:

- Катмыш, Баскан, Еникей Чишмә торак пунктларында пожар гидрантлары урнаштыру.

« ӘЙЕ » « ЮК »

2. Әлеге карарны муниципаль берәмлек Советының мәгълүмат стендларында, Мамадыш муниципаль районы mamadysh.tatarstan.ru сайтында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru.) сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен Мамадыш муниципаль районы Катмыш авыл җирлеге башлыгы И.Г. Габидуллинга йөкләргә.

Мамадыш муниципаль районы
Катмыш авыл җирлеге башлыгы,
Совет председателе Габидуллин И.Г.